КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 май г.Казань № 280

Мәҗбүри медицина иминиятләвенең база программасына керми торган авыруларда медицина тернәкләндерүе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт медицина оешмалары базасында гамәлгә ашырыла торган медицина тернәкләндерүе өлешендә гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Мәҗбүри медицина иминиятләвенең база программасына керми торган авыруларда медицина тернәкләндерүе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне), хроник бавыр эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ, хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга перитонеаль диализ оештыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» 2011 ел, 29 декабрь, 1091 нче карарының 1 пунктының икенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 6 май, 300 нче карарның 5 пунктындагы икенче, өченче абзацлар;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарны медицина-социаль һәм психологик тернәкләндерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү

сыйфаты стандартын раслау турында» 2012 ел, 13 октябрь, 851 нче карары.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин